РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**СОВЕТ БОЛЬШЕЧЕКМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ЧАКМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

---

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ЧАКМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ V ЧАКЫРЫЛЫШ VII УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 12**

Олы Чакмак авылы «19» март 2026 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлеге Советының 2018 елның «26» ноябрьдә «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 25 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 28.11.2025 №425-ФЗ Федераль законына таянып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы прокурорының 02.03.2026 елгы протестын үтәү йөзеннән 02-08-01-2026, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Олы Чакмак авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлеге Советының 2018 елның «26» ноябрьдә «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 25 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1 2 пунктның 2 пунктчасындагы 5 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган салым салу объектлары, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш”

2.Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында чыгару.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Олы Чакмак авыл җирлеге башлыгы** **И.М.Габидуллин**